**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь № 664

г. Казань

2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү фаразы, 2016 елга Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты фаразы, 2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турында

2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү фаразы турында Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары О.В.Пелевин докладын, 2016 елга Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты фаразы турында Татарстан Республикасы финанс министры Р.Р.Гайзатуллин докладын, 2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проекты турында «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе директоры докладын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга һәм 2017 һәм 2018 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү фаразын, 2016 елга Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджеты фаразын, 2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты проектын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2015 елның 14 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын, әлеге закон проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документлар һәм материаллар белән, кертергә.

3. Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, 2015 елның 14 сентябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына «2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\664.docx